ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05. 12. 2019 г.Мензелинск № 1104

**ТР Минзәлә муниципаль районының
“Кояшкай” 8 нче номерлы гомуми үстерешле төрдәге балалар
бакчасы” МБМБУ Уставын яңа редакциядә
раслау турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131 нче номерлы Федераль законы нигезендә, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273 нче номерлы Федераль законы нигезендә, Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Кояшкай” 8 нче номерлы гомуми үстерешле төрдәге балалар бакчасы” Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе Уставын яңа редакциядә расларга.
2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Кояшкай” 8 нче номерлы гомуми үстерешле төрдәге балалар бакчасы” МБМБУ мөдире Подгорная Яна Владимировнага әлеге карар кабул ителгәннән соң өч эш көне дәвамында юридик затларның дәүләт теркәвен башкаручы органга (Россия Федераль Салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча районара инспекциясе) яңа редакциядә Уставны раслау турында билгеләнгән тәртиптә хәбәр итү вәкаләтен бирергә.
3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 18.03.2019 елдагы 282 номерлы карарын көчен югалткан дип танырга.
4. .Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районының “Мәгариф бүлеге” Муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Н.С.Габдуллинга йөкләргә.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев.